КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче
Татар Икшермә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

24.11.2025 ел № 2

2025 елның 20 мартында кабул ителгән №33-ФЗ «Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән №45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның №36 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2025 елның 24 ноябрендә узган гражданнар җыенында

«2026 нчы елда Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Татар Икшермә торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Татар Икшермә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йез) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт территориясен тезекләндерү (Татар Икшермәсе торак пунктында урнашкан балалар мәйданчыгын төзекләндерү һәм җиһазлау)» мәсьәләсен «2026 нчы елда Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Татар Икшермә торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Татар Икшермә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Татар Икшермәсе торак пунктында урнашкан балалар мәйданчыгын тезекләндерү һәм җиһазлау),

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Икшермәсе торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау)» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә тезелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 189 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 107 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 107 се тавыш бирде;
- «Юк» позициясе ечен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Татар Икшермә торак пунктында гражданнар җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2026 нчы елда Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Татар Икшермә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Татар Икшермәсе торак пунктында урнашкан балалар мәйданчыгын төзекләндерү һәм җиһазлау),

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Икшермәсе торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау)» - дигән сорауны кабул ителгән дип танырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенында рәислек итүче,
Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы: А.И.Биккинин